Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Нәдер авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

08 ноябрь 2019 ел N 1

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге Яңа Нәдер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 23 ноябрендә, 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылында Г.Абдуллина, Киров, Кыр, Сөембикә, Яшьләр һәм С.Сөләйманова урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 24 ноябрендә, 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылында Ш.Усманов, М.Җәлил, Х.Рахманов, Г.Тукай, Күл һәм Елга урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 30 ноябрендә, 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылында Совет, Комсомол, Зәй, Куйбышев, Партизан, Пионер һәм Урман урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: су насослары сатып алу, вак ташлы юлларны норматив хәлгә китерү, асфальт түшәмле чокырларны ремонтлау, юл билгеләре куелып ясалма тигезсезлекләр төзү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын Яңа Нәдер авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 95 нче йорт.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 95 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Яңа Нәдер
авыл җирлеге башлыгы С.М. Миннебаев